# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Иштуган авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

25 ноябрь, 2025 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иштуган авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. «Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Иштуган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 1 Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү - халыкның күпләп ял итү урыннарын, парклар, скверлар, спортһәм уен мәйданчыклары, халыкның башка күпләп ял итү урыннарын карап тоту, төзү, ремонтлау, төзекләндерү), проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү; территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре), (балалар мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазлау, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Иштуган авылы балалар мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (чишмәләрне ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, (будка сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын

проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иштуган авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иштуган авылының Куйбышев урамында юлларны рәтләү, ремонтлау һәм вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, дренаж системасы ясау, эш өчен шартнамә буенча түләү, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны карап тоту, яктырткычлар һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Нырья авыл җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы: П.П. Кузьмин